**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 9 июнендәге 1954 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 9 февралендәге 425 номерлы «Күпфатирлы йортта торакны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, муниципаль хезмәтләрдән һәркем файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 9 февралендәге 425 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта торакны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 3 апрелендәге 1003 номерлы һәм 2026 елның 16 февралендәге 458 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 10 номерлы кушымтаны әлеге карар кушымтасы нигезендәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы Р.Х.Шәмсетдиновка, Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы А.И.Салиховка, Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы В.В.Жаворонковка, Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы Р.Р.Фәтхетдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 9 июнендәге
1954 номерлы карарына
кушымта

**Күпфатирлы йортта торакны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазифаи затларның реквизитлары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Администрация башлыгы | 223-22-33 | avia.novsav@tatar.ru |
| Муниципаль хезмәтләр бүлеге башлыгы | 223-22-33 | avia.novsav@tatar.ru |

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Администрация башлыгы | 223-21-11 | vah-pri.adm@tatar.ru |
| Торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы | 223-21-11 | vah-pri.adm@tatar.ru |

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Администрация башлыгы | 223-29-99 | km.r@tatar.ru |
| Торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы | 223-29-99 | km.r@tatar.ru |

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
Совет районы администрациясе**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Администрация башлыгы | 223-20-00 | Sov.Post@tatar.ru |
| Муниципаль хезмәтләр бүлеге башлыгы | 223-20-00 | Sov.Post@tatar.ru |